**5 нче сыйныф эш программасына аннотация (рус төркеме)**

**Эш программасында исәпләнгән сәгатьләр саны:** программа базис план буенча атнага 1, елга 3 5 сәгать исәбеннән төзелде.

**УМК**: 1.Татар теле:Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 2 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.Х Хәйдәрова, Н.Г.Галиева, Г.М. Ахметзянова - Казан: «Татармультфильм» нәшрияты, 2017.

2. VIIIтөр (коррекцияләү) рус гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-9 сыйныфлар Казан: РИЦ «Школа», 2009 г.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары**

1) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;

2) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;

3) программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;

4) карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;

5) татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;

6) татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;

7) халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

**5 нче сыйныф укучылары үзләштерергә тиешле грамматик минимум.**

1. Темалар буенча өйрәнелгән берлек һәм күплек саннадагы исемнәрне гамәли үзләштерү.
2. Уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен, килеш белән төрләндереп, сөйләмдә куллану.
3. Исемнәргә кем? яки нәрсә? сорауларын куярга өйрәнү.
4. Исемнәргә –ныкы, - неке кушымчаларын ялгап, кемнеке? Соравына җавап бирергә күнектерү.
5. –мы,-ме, түгел кисәкчәләрен җөмләләрдә дөрес куллану; аларда басымны дөрес куярга өйрәнү.
6. Зат алмашлыкларына –ныкы,-неке кушымчаларн ялгап, аларны дөрес куллануга ирешү.
7. Сорау алмашлыклары белән җөмләләр төзүгә күнектерү, аларда басымның беренче иҗеккә төшү үзенчәлеген белү.
8. Сан+исем төзелмәсен сөйләмдә куллана белү.
9. Лексик темаларга караган сыйфатларны сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.
10. Сыйфат+исем төзелмәсен гамәли үзләштерү.
11. Белән, турында бәйлекләренең исем белән кулланышын үзләштерү.
12. Кирәк (кирәк түгел), ярый (ярамый), мөмкин кебек модаль сүзләрне фигыльнең инфинитив формасы белән бергә кулланырга өйрәнү.
13. Алдында, артында, астында, өстендә бәйлек сүзләре белән җөмләләр төзергә күнектерү.
14. Ләкин, чөнки теркәгечле кушма җөмләләрнең эчтәлеген аңлап, аларны сөйләмдә куллануга ирешү.
15. Татар һәм рус телләрендә җөмләдә сүз тәртибенең үзенчәлекләрен аера һәм аңлый белүгә гадәтләндерү.
16. Татар җөмләсендә сүз тәртибен гамәли үзләштерү.
17. Раслау, инкарь, сорау, хикәя, боерык җөмлә төрләрен сөйләмдә куллануга ирешү.

18. Хикәя, сорау, өндәү җөмлә калыпларын дөрес интонация белән әйтергә күнектерү.

**6 нче сыйныф эш программасына (татар теле) аннотация (рус төркеме)**

**Эш программасында исәпләнгән сәгатьләр саны:** программа базис план буенча атнага 1, елга 3 5 сәгать исәбеннән төзелде.

**УМК**: 1.Татар теле:Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 2 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.Х Хәйдәрова - Казан: «Мщгариф» нәшрияты, 2009.

2. VIIIтөр (коррекцияләү) рус гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-9 сыйныфлар Казан: РИЦ «Школа», 2009 г.

**МАКСАТЫ** : телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә , уку хезмәтенә бәйле ситуацияләре кысаларында белем бирү , күнекмәләр формалаштыру, татар теле фәненә кыскача характеристика, белем бирү максат һәм бурычларын чишкәндә әһәмияте һәм үзенчәлеге.

ГОМУМИ БЕЛЕМ БИРҮ максаты: акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен үстерү, сөйләм культурасын үстерү.

ТӘРБИЯВИ максат: балаларның рухи дөньяларын баету, татар халкының мәдәнияте, сәнгате белән таныштыру,төрле милләт вәкилләре арасында дуслык һәм хөрмәт хисе тәрбияләү.

**БУРЫЧЛАР** :

1)өйрәнелгән материалга нигезләнгән татар сөйләмен укытучыдан яки башка укучылардан ишетеп аңлау;

2)диалогик, монологик сөйләм күнекмәләрен формалаштыру;

3)текстларны сәнгатьле итеп, аңлап укый белү күнекмәләрен булдыру;

4)татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;

Укыту эшчәнлеген оештыру гадидән катлаулыга таба юнәлтелә, 5 нче сыйныфта өйрәнелгән грамматик материалны системалаштыру, ныгыту, тирәнәйтү бурычы күздә тотыла, укыту балаларның шәхси - психологик үзенчәлекләрен исәпкә алып оештырыла; Уңышка ирешү өчен тел дәресләрен уку дәресләре белән тыгыз алып бару отышлы. Татар теле дәресләрендә өйрәнгән грамматик структуралар уку дәресләрендә сөйләмдә ныгытыла, лексик материал активлаштырыла.

**6 сыйныф укучысы үзләштерергә тиешле лексик – грамматик минимум.**

1. Сан, тартым белән төрләнгән исемнәргә килеш кушымчаларын ялгау тәртибен гамәли үзләштерү апа-лар-ым-ны.
2. Зат алмашлыкларының килеш белән төрләнүен кабатлау.
3. Алмашлыкларның җөмлә төзүдә куллану үзенчәлекләрен белү.
4. Хәзерге заман хикәя фигыльне сөйләмдә дөрес куллану күнекмәләрен ныгыту.
5. Билгеле һәм билгесез үткән заман хикәя фигыльләрне зат һәм сан белән төрләндереп, сөйләм оештыру өстендә эшләү.
6. Баш һәм юнәлеш килешләрен таләп итүче бәйлекләрне танып белергә һәм сөйләмдә файдаланырга күнектерү.

7. –даш/-дәш, -таш/-тәш, -лык/-лек, -кыч/-кеч кушымчалары ярдәмендә ясалган исемнәрнең, кушма сүзләрнең (башваткыч, тизәйткеч), парлы сүзләрнең (тиз-тиз) мәгънәләренә төшендерү. Аларны русчага дөрес тәрҗемә итәргә өйрәтү.
8. Бу, шул, теге алмашлыкларының килеш формаларын истә калдыру.
9. Җөмләнең баш кисәкләрен табарга, аларны төрле сүз төркемнәре белән белдерергә һәм рус теле белән чагыштырырга өйрәтү.
10. Хикәя, боерык, сорау җөмләләрдә сүз тәртибе үзенчәлекләрен рус теле белән чагыштырып өйрәтү.

## 7 сыйныф татар теле буенча эш программасына аннотация.

**Эш программасында исәпләнгән сәгатьләр саны:** программа базис план буенча атнага 1, елга 3 5 сәгать исәбеннән төзелде.

**УМК**: Татар теле:Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 4 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.Х Хәйдәрова ,З.Р.Назипова.- Казан: «Татармультфильм» нәшрияты, 2017.

**Эш программасының максаты һәм бурычлары**

Рус телле балаларга татар телен укытуның төп максаты: укучыларны татарча аралашырга өйрәтү,татар теленең орфоэпик, орфографик.лексик, грамматик нигезләрен системалы рәвештә үзләштерү,телдән һәм язма сөйләм осталыгы һәм күнекмәләрен камилләштерү, татар теленә хөрмәт тәрбияләү, бу телнең дәүләт теле буларак әһәмияте зур булуына төшендерү.

Бу максатка ирешү өчен, түбәндәге бурычларны хәл итү сорала:

8) татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү;

9) татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;

10)программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;

11)карап чыгу, танышу, өйрәнү, эзләнү максаты белән уку төрләрен кулланып, төрле жанрдагы текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;

12)татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;

13)татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;

14)халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү.

**7 нче сыйныфны тәмамлаганда укучыларның үзләштерергә тиешле минимумы:**

**<u>Грамматик минимум</u>**

1. *Башында, уртасында, ахырында* бәйлек сүзләрен сөйләмдә куллану.
2. Лексик темаларга караган сыйфатларны артыклык, чагыштыру дәрәҗәләрендә кулланырга өйрәтү.
3. Боерык фигыльнең барлык, юклык формалары.
4. Кушма, парлы исемнәрне, мәгънәләрен аңлап, дөрес кулланырга ирешү.

5. *Биредә, тегендә, монда, анда* рәвешләрен сөйләмдә кулллануны ныгыту.
6. Актив үзләштерелгән исемнәрнең тартым белән төрләнешен гамәли белүне ныгыту.
7. Фигыльнең өйрәнелгән заман формаларын аңлап аера белү һәм дөрес белдерү өчен кирәкле формаларны сайлап кулланырга күнектерү.
8. Саннарның өйрәнелгән төркемчәләрен гамәли белүне ныгыту.
9. Зат алмашлыкларын килешләр белән төрләндереп, дөрес куллануга ирешү.
10. Берлек һәм күплек сандагы уртаклык һәм ялгызлык исемнәрен, тартым һәм килеш белән төрләндереп, сөйләмдә куллану күнекмәләрен системалаштыру.

**<u>Орфографик һәм орфоэпик минимум</u>**

1. Сузык һәм тартык авазлар. Татар теленең үзенчәлекле авазларын кабатлап тору.
2. Сүзләрнең иҗекләргә бүленешен истә тотып, сөйләм оештыра белү.
3. Сүзләрнең басымын билгеләү. Басымның гамәли очракларын белү.
4. Сингармонизм законының асылын гамәли белү.
5. Хәрефләрне, сүзләрне, җөмләләрне каллиграфик дөрес итеп яза белүне камилләштерү.
6. Сүзләрнең грамматик мәгънәләрен үзгәртә торган мөнәсәбәт белдерүче кушымчаларны (исемнәрдә - күплек сан, килеш; фигыльләрдә - юклык, заман, зат-сан) дөрес билгеләү күнекмәләрен булдыру.
7. Җөмлә ахырында нокта, сорау яки өндәү билгеләрен куеп, язу күнекмәләрен гомумиләштерү.

### 8 сыйныф татар теле буенча эш программасына аннотация

**Эш программасында исәпләнгән сәгатьләр саны:** программа базис план буенча атнага 1, елга 3 5 сәгать исәбеннән төзелде.

**УМК**: 1.Татар теле:Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 5 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.Х Хәйдәрова - Казан: «Татарстан китап» нәшрияты, 2011.

2. VIIIтөр (коррекцияләү) рус гомуми белем бирү мәктәбендә татар теле укыту программасы (рус телендә сөйләшүче балалар өчен) 1-9 сыйныфлар Казан: РИЦ «Школа», 2009 г.

***Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теле укытуның төп максаты һәм бурычлары***

- укучыларның башлангыч мәктәптә үзләштергән белемнәрен һәм сөйләм күнекмәләрен камилләштерү;
- татар этикеты тәгъбирләрен кертеп, бирелгән ситуация буенча диалогик сөйләм оештырырга өйрәтү;
- программада күрсәтелгән лексик темалар буенча телдән яки язмача монологик сөйләм булдыруга ирешү;
- татар сөйләмен тыңлап аңларга күнектерү, текстларны аңлап уку күнекмәләрен үстерү;
- татар телендәге сөйләмне фонетик, лексик, грамматик яктан дөрес төзергә күнектерү;
- татар халкының фән, мәгариф, сәнгать, мәдәният өлкәсендәге казанышлары, күренекле шәхесләре белән таныштыруны дәвам итү;
- халыкларның үзара аңлашып, тату яшәвенә омтылыш тәрбияләү
- укучыларның татар телен өйрәнүгә ихтыяҗын арттыру.

***Белем бирү эчтәлегенең мәҗбүри минимумы***

**Тыңлап аңлау.** Аерым сүзләрне, җөмләләрне тыңлап тәрҗемә итә белү; бәйләнешле текстны тыңлап, эчтәлеге буенча укытучының сорауларына җавап бирү; дәрес барышында җанлы сөйләмне аңлап аралаша белү.

**Диалогик һәм монологик сөйләм.** Сорау һәм җавап репликаларын дөрес кулланып, әңгәмә төзи белү; тәкъдим ителгән ситуация буенча сөйләшү үткәрү (һәр укучының репликалар саны җидедән ким булмаска тиеш); укылган (тыңланган) текстның эчтәлеген сөйләп бирү, лексик тема буенча бәйләнешле текст төзеп сөйләү (җөмләләр саны сигездән ким булмаска тиеш).
**Уку.** Татар теленең әйтелеш нормаларын үтәп, аерым җөмләләрне диалогик һәм монологик текстларны сәнгатьле итеп һәм аңлап уку; таныш булмаган сүзләрнең мәгънәләрен сүзлекләрдән табып аңлата белү.
**Язу.** Лексик темага караган һәм актив үзләштерелгән сүзләрнең язылышын истә калдыру, укылган текстның эчтәлеге буенча сорауларга язмача җавап бирү яки сөйләү, грамматик биремле диктантлар язу.

## 9 сыйныф татар теленнән эш программасына аннотация.

**Эш программасында исәпләнгән сәгатьләр саны:** программа базис план буенча атнага 1, елга 3 5 сәгать исәбеннән төзелде.

**УМК**: Татар теле:Рус телендә урта гомуми белем бирүче мәктәпнең 6 нчы сыйныфы өчен дәреслек (рус телендә сөйләшүче балалар өчен)/Р.Х Хәйдәрова ,З.Р.Назипова.- Казан: «Татармультфильм» нәшрияты, 2017.

**Рус телендә сөйләшүче балаларга татар теленә өйрәтүнең төп максаты** – гамәли максат : телне аралашу чарасы буларак үзләштерү өчен, укучыларга гаилә-көнкүрешкә, уку хезмәтенә бәйле ситуацияләре кысаларында белем бирү, күнекмәләр формалаштыру.

**Гомуми белем бирү максаты**: укучыларның гомуми белем мәктәбендә үзләштерелгән белемнәрен камилләштерү һәм тирәнәйтү;тел күренешләрен танып белергә, чагыштырырга, гомумиләштерергә күнектерү;татар телен халыкның рухи, әхлакый, мәдәни хәзинәсе буларак аңларга ирешү;алган белемнәрне аралашу да кулланырга өйрәтү;укучыларның акыл эшчәнлеген активлаштыру, логик фикерләү сәләтен үстерү, сөйләм культурасын үстерү.

**Уку елы ахырында көтелгән нәтиҗәләр:**

1.Җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләренең исемнәрен әйтә, сорау куя,аера белү.

2.Гади һәм кушма җөмләләрне аера белергә өйрәтү.

3.Теркәгечле һәм теркәгечсез тезмә кушма җөмләләрне сөйләмдә куллана белү күнекмәләрен булдыру. 4.Җыючы, каршы куючы, бүлүче теркәгечле кушма җөмләләрне сөйләмдә куллану.

5.Иярчен хәл җөмләләрнең иярчен вакыт җөмлә, урын җөмлә, максат җөмлә, шарт җөмлә, сәбәп җөмлә, кире җөмләләре белән таныштыру һәм аларны әдәби текстларда тануга ирешу, сөйләмдә урынлы куллануга ирешү.

6.Тезмә һәм иярченле кушма җөмләләрдә тыныш билгеләрен дөрес кую һәм аларны тиешле интонация белән әйтү.

**Контроль төрләре:** контроль язма эшләр